КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 16 декабрь г.Казань № 1151

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 5 март, 137 нче; 2018 ел, 4 сентябрь, 746 нчы; 2018 ел, 3 ноябрь, 979 нчы; 2018 ел, 21 декабрь, 1200 нче; 2018 ел, 28 декабрь, 1252 нче; 2019 ел, 12 февраль, 98 нче; 2019 ел, 24 май, 438 нче; 2019 ел, 9 июль, 559 нчы; 2019 ел, 18 сентябрь, 849 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) ашлык киптерү комплексларын газлаштыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) үсемлекләрне саклау чаралары эремәләрен һәм агрохимикатлар әзерләү өчен стационар эремә үзәкләрен булдыру буенча материаллар һәм җайланмалар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен»;

әлеге карарга Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) ашлык киптерү комплексларын газлаштыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен һәм Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) үсемлекләрне саклау чаралары эремәләрен һәм агрохимикатлар әзерләү өчен стационар эремә үзәкләрен булдыру буенча материаллар һәм җайланмалар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен (карарга теркәләләр) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин